| УКАЗ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>УКАЗЫ |
|---|---|

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплексլы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы ПУ-189 номерлы, 2020 елның 30 мартындагы ПУ-218 номерлы һәм 2021 елның 29 маендагы ПУ-415 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| **11** | **Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе******* |

»;

б) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| **21** | **Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгы Идел буе-Урал төбәкара территориаль идарәсенең Татарстан Республикасындагы һәм Удмуртия Республикасындагы бүлеге (инспекциясе) ******* |

»;

в) түбәндәге эчтәлекле астөшермә өстәргә:

«*****Эшчәнлеккә мониторинг Татарстан Республикасы буенча мәгълүматлар өлешендә уздырыла.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ ПУ-220